**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ ПР-20 04.02.2025 КАРАР №______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында әлеге карарга 1, 2, 3 номерлы кушымталар нигезендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2025 елның 1 февраленнән 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»2024 елның 01 февралендәге ПР-17 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________ №____
1 нче кушымта

01.02.2025 елдан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 6492,75 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү | 921,11 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1751,51 |
| БАРЛЫГЫ | 9165,37 |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
_______________ №_____
2 кушымта

01.02.2025 елдан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Кәфенләү | 521,03 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү. | 2720,67 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү. | 1389,40 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4534,27 |
| БАРЛЫГЫ | 9165,37 |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___ __________ 2025ел, №__
3 нче кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| № т/б | Авыл җирлекләре атамасы | Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1. | Аеш | 9165,37 сум |
| 2. | Аккүз | |
| 3. | Актаныш | |
| 4. | Актанышбаш | |
| 5. | Әтәс | |
| 6. | Югары Яхшый | |
| 7. | Кәзкәй | |
| 8. | Киров | |
| 9. | Күҗәкә | |
| 10. | Мәсәде | |
| 11. | Яңа Әлем | |
| 12. | Пучы | |
| 13. | Иске Айман | |
| 14. | Иске Байсар | |
| 15. | Иске Богады | |
| 16. | Иске Сәфәр | |
| 17. | Иске Кормаш | |
| 18. | Такталачык | |
| 19. | Татар Ямалысы | |
| 20. | Теләкәй | |
| 21. | Татар Суыксуы | |
| 22. | Түке | |
| 23. | Уразай | |
| 24. | Усы | |
| 25. | Чалманарат | |
| 26. | Чуракай | |